## Вступительное слово к изданию Гражданского процессуального кодекса РФ на татарском языке – государственном языке Республики Татарстан

Язык, будучи основным средством коммуникации, предоставляет его носителю самый широкий спектр возможностей для реализации его субъективных прав и исполнения обязанностей. Действующее федеральное законодательство предусматривает комплекс мер, направленных на развитие языков субъектов РФ. В частности, часть 2 статьи 26 Конституции РФ определяет, что каждый имеет право на пользование родным языком, на свободный выбор языка общения, воспитания, обучения и творчества. Исходя из положений части 2 статьи 68 Конституции РФ республики в составе РФ вправе устанавливать свои государственные языки. В органах государственной власти, органах местного самоуправления, государственных учреждениях республик они употребляются наряду с государственным языком Российской Федерации.

Предполагается, что указанные языковые гарантии распространяются на все стороны общественной жизни, включая возможность принудительной защиты нарушенного субъективного права либо права, в отношении которого существует угроза его нарушения. Реализация права на судебную защиту является важнейшей конституционной гарантией, определяющей возможные способы защиты прав, свобод и законных интересов.

Гражданский процессуальный кодекс РФ предусматривает также ряд языковых гарантий для участников процессуальных отношений, в том числе возможность рассмотрения дела на государственном языке республики, которая входит в состав Российской Федерации и на территории которой находится соответствующий суд.

В рамках наших научных исследований был проведен опрос Верховных судов республик, субъектов Российской Федерации, имеющих свои государственные языки по вопросу использования государственного языка субъекта РФ при реализации права на судебную защиту в порядке гражданского судопроизводства. По результатам данного опроса можно заключить, что в настоящее время отсутствуют пере-

воды Гражданского процессуального кодекса РФ на государственные языки субъектов РФ, что приводит к отсутствию терминологического аппарата способного установить единую юридическую лексику на государственном языке субъекта РФ.

Представленный труд является первым официальным переводом Гражданского процессуального кодекса РФ на государственный язык субъекта РФ – татарский язык – государственный язык Республики Татарстан. Надеемся, что указанный перевод будет полезен для судов, участников судопроизводства и в целом для российского общества, и будет способствовать дальнейшей работе субъектов РФ по переводу Гражданского процессуального кодекса РФ на государственные языки субъектов РФ в целях реализации языковых гарантий, установленных Конституцией РФ.

Если будут какие-либо предложения, замечания по указанному изданию, просим их направлять на адрес электронной почты: Perevod.GPK@yandex.ru. Заранее благодарны всем неравнодушным.

С уважением

*д.ю.н., профессор, руководитель проекта*
*«Реализация конституционного права на судебную защиту*
*по гражданским делам на государственных языках субъекта РФ»,*
*член Научно-консультативного совета*
*при Верховном Суде Республики Татарстан*

***Д.Х. Валеев***

# РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ ГРАЖДАН ПРОЦЕССУАЛЬ КОДЕКСЫ

*Дәүләт Думасы тарафыннан*
*2002 елның 23 октябрендә*
*кабул ителде*

*2002 елның 30 октябрендә*
*Федерация Советы тарафыннан хупланды*

Россия Федерациясе Конституция Судының 18.07.2003 № 13-П, 27.01.2004 № 1-П, 25.02.2004 № 4-П, 26.12.2005 № 14-П карарлары, Россия Федерациясе Конституция Судының 13.06.2006 № 272-О билгеләмәсе, Россия Федерациясе Конституция Судының 12.07.2007 № 10-П, 27.02.2009 № 4-П, 19.03.2010 № 7-П, 21.04.2010 № 10-П карарлары, Россия Федерациясе Конституция Судының 01.03.2012 № 5-П, 22.04.2013 № 8-П карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

## I өлеш. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### 1 бүлек. ТӨП НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

#### 1 статья. Граждан суд эшчәнлеге турындагы законнар

1. Граждан суды эшчәнлеге тәртибе Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясе суд системасы турында» Федераль конституциячел закон, әлеге Кодекс һәм алар нигезендә кабул ителә торган башка федераль законнар, җәмәгать судьясының граждан суд эшчәнлеге тәртибе, шулай ук «Россия Федерациясе җәмәгать судьялары турында»гы Федераль закон белән билгеләнә.

2. Әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе белән граждан суд эшчәнлегенең законда каралганнан башка башка кагыйдәләр билгеләнгән булса, халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

3. Граждан суд эшчәнлеге граждан эшен караган һәм хәл иткән, аерым процессуаль гамәлләр кылган яисә суд карарларын (суд боерыкларын, суд карарларын, суд билгеләмәләрен, күзәтчелек инстанциясе суды президиумының карарларын), башка органнарның карарларын үтәгән вакытта гамәлдәге федераль законнар нигезендә алып барыла.

4. Граждан суд эшчәнлеге барышында барлыкка килгән мөнәсәбәтләрне җайга салучы процессуаль хокук нормасы булмаган очракта, гомуми юрисдикциядәге федераль судлар һәм җәмәгать судлары (алга таба шулай ук – суд) охшаш мөнәсәбәтләрне җайга салучы норманы (закон аналогиясе), ә мондый норма булмаганда, Россия Федерациясендә хөкем итүне гамәлгә ашыру принципларыннан чыгып (хокук аналогиясе) эш итәләр.

### 2 статья. Граждан суд эшчәнлеге бурычлары

Граждан суд эшчәнлеге бурычлары гражданнарның, оешмаларның бозылган яисә дәгъвалана торган хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен, Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең, граждан, хезмәт яисә башка хокук-мөнәсәбәтләре субъектлары булып торган башка затларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатларында граждан эшләрен дөрес итеп һәм үз вакытында караудан һәм хәл итүдән гыйбарәт. Граждан суд эшчәнлеге законлылык һәм хокук тәртибен ныгытуга, хокук бозуларны кисәтүгә, законга һәм судка ихтирамлы мөнәсәбәт булдыруга ярдәм итәргә тиеш.

### 3 статья. Судка мөрәҗәгать итү хокукы

1. Кызыксынучы зат бозылган йә дәгъвалана торган хокукларын, ирекләрен яисә законлы мәнфәгатьләрен яклау өчен граждан суд эшчәнлеге турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

1.1. Дәгъва гаризасы, гариза, шикаять, күрсәтмә һәм башка документлар судка кәгазьдә яисә электрон рәвештә, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә судның рәсми сайтында урнаштырылган форманы тутырып, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә электрон имза куелып, тапшырылырга мөмкин.

2. Судка мөрәҗәгать итү хокукыннан баш тарту дөрес булмый.

3. Граждан эшен асылы буенча карауны тәмамлый торган беренче инстанциядәге суд карары суд тарафыннан кабул ителгәнчегә кадәр, граждан-хокук мөнәсәбәтләреннән барлыкка килгән бәхәс яклар килешүе буенча, әгәр әлеге Кодекста һәм федераль законда башкача билгеләнмәгән булса, яклар тарафыннан третейский суд каравына тапшырылырга мөмкин;

4. Гариза судка бәхәсне җайга салуның дәгъва белдерү яисә судка кадәрге башка тәртибен үтәгәннән соң, әгәр бу әлеге категориядәге бәхәсләр өчен федераль закон белән каралган булса, бирелә.

5. Судка мөрәҗәгать иткәннән соң яклар бәхәсне хәл итү өчен килештерү процедуралары кулланырга хокуклы.

**4 статья. Судта граждан эшен башлау**

1. Суд үз хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өчен мөрәҗәгать иткән зат гаризасы буенча граждан эше башлана.

2. Әлеге Кодекста, башка федераль законнарда каралган очракларда граждан эше башка затның, билгесез затлар даирәсенең хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклап яисә Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең мәнфәгатьләрен яклап үз исеменнән чыгыш ясаучы зат гаризасы буенча башланырга мөмкин.

**5 статья. Суд эшен бары тик судлар тарафыннан гына башкару**

Гомуми юрисдикциядәге судлар компетенциясенә карый торган граждан эшләре буенча суд эше граждан суд эшчәнлеге турындагы законнарда билгеләнгән кагыйдәләр буенча бары тик әлеге судлар тарафыннан гына башкарыла.

**6 статья. Закон һәм суд алдында һәркемнең тигезлеге**

Граждан эшләре буенча суд эше кешенең җенесенә, раса, милләтенә, теленә, килеп чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә, яшәү урынына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, иҗтимагый берләшмәләрдә торуына һәм башка хәлләргә бәйсез рәвештә барлык гражданнарның, шулай ук оештыру-хокукый рәвешенә, милек рәвешенә, урнашкан урынына, кемгә буйсынуына һәм башка хәлләргә бәйсез рәвештә барлык оешмаларның закон һәм суд каршында бертигез булуына шартларында гамәлгә ашырыла.

### 6.1 статья. Суд эшчәнлегенең билгеле вакыты һәм суд карарын үтәүнең билгеле вакыты

1. Судларда суд эшчәнлеге һәм суд карарын үтәү билгеле вакытларда башкарыла.

2. Судларда эшләрне тикшерү әлеге Кодекста билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла. Әлеге вакытлар әлеге Кодекста билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә озайтылырга мөмкин, ләкин суд эшчәнлеге билгеле вакытларда гамәлгә ашырылырга тиеш.

3. Суд тикшерүенең билгеле вакытларын ачыклаганда, ә аңа дәгъва гаризасы яисә беренче инстанция судына гариза кергән көннән алып эш буенча соңгы суд карары кабул ителгән көнгә кадәр булган чор керә, эшнең хокукый һәм фактик катлаулылыгы кебек сәбәпләр, граждан процессында катнашучыларның тәртибе, эшне үз вакытында карау максатында гамәлгә ашырыла торган суд гамәлләренең җитәрлек булуы һәм нәтиҗәлелеге һәм эш буенча суд эшчәнлегенең гомуми дәвамлылыгы исәпкә алына.

4. Суд эшен оештыруга, шул исәптән судьяны алмаштыруга бәйле сәбәпләр, шулай ук эшне төрле инстанцияләрдә карау эш буенча суд эшчәнлегенең билгеле вакытын арттыру өчен нигез буларак игътибарга алына алмый.

5. Эш буенча әлеге статьяның өченче һәм дүртенче өлешләрендә каралган суд эшчәнлегенең билгеле вакытын ачыклау кагыйдәләре суд актларын үтәүнең билгеле вакытларын ачыклаганда да кулланыла.

6. Дәгъва гаризасы яисә башкаруга алу гаризасын кабул итеп алганнан соң эш озак вакыт каралмаган һәм суд барышы озакка сузылган очракта, кызыксынучы зат эшне карауны тизләтү турындагы гариза белән суд рәисенә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

7. Эшне карауны тизләтү турындагы гаризаны суд рәисе судка гариза кергән көннән алып биш көн эчендә карый. Гаризаны карау нәтиҗәләре буенча суд рәисе расланган билгеләмә чыгара, анда эш буенча суд утырышын үткәрү вакыты билгеләнергә һәм (яисә) суд тикшерүен тизләтү өчен башкарылырга тиешле эшләр күрсәтелергә мөмкин.

### 7 статья. Граждан эшләрен шәхсән һәм коллегиаль тәртиптә карау

1. Беренче инстанция судларында граждан эшләре әлеге судларның судьялары тарафыннан шәхсән яисә федераль законда каралган очракларда коллегиаль карала.

2. Әгәр әлеге Кодекс белән судьяга граждан эшләрен шәхсән карау һәм аерым процессуаль гамәлләр кылу хокукы бирелгән булса, судья суд исеменнән эш итә.

3. Җәмәгать судьяларының закон көченә кермәгән суд карарларына шикаятьләр буенча эшләр апелляция тәртибендә тиешле район суды судьялары тарафыннан шәхсән карала.

4. Апелляция инстанциясе судларында граждан эшләре, әлеге Кодексның шушы статьясындагы өченче өлеше, 333 статьясындагы дүртенче өлеше, 335.1 статьясындагы беренче өлеше, 379.5 статьясындагы унынчы өлешендә каралган очраклардан тыш, коллегиаль карала.

Күзәтчелек инстанциясе судындагы граждан эшләре коллегиаль карала.

**8 статья. Судьяларның бәйсезлеге**

1. Суд эшен караганда суд эшчәнлегендә судьялар бәйсез була һәм бары тик Россия Федерациясе Конституциясенә һәм федераль законга гына буйсыналар.

2. Судьялар граждан эшләрен аларга читтән йогынты ясау булмаган шартларда карыйлар һәм хәл итәләр. Суд эше каралганда судьялар эшчәнлегенә теләсә ничек тыкшыну тыела һәм законда билгеләнгән җаваплылыкка китерә.

3. Судьяларның бәйсезлек гарантияләре Россия Федерациясе Конституциясе һәм федераль закон белән билгеләнә.

4. Дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, башка органнарның, оешмаларның, вазыйфаи затларның яисә гражданнарның судьялар каравындагы граждан эшләре буенча аларга, йә суд рәисенә, аның урынбасарына, суд каравындагы граждан эшләре буенча суд составы рәисенә яисә суд коллегиясе рәисенә кергән суд барышына кагылмаган мөрәҗәгатьләр турындагы мәгълүмат хәбәрдарлыкка ия булырга тиеш һәм ул, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә судның рәсми сайтына урнаштырылып, суд тикшерүендә катнашучылар игътибарына җиткерелергә тиеш һәм ул граждан эшләре буенча процессуаль гамәлләр кылу яисә процессуаль карарлар кабул итү өчен нигез булып тора алмый.

**9 статья. Граждан суд эшчәнлеге теле**

1. Граждан суд эшчәнлеге рус телендә — Россия Федерациясенең дәүләт телендә яисә Россия Федерациясе составына керә торган һәм территориясендә тиешле суд урнашкан республиканың дәүләт телендә алып барыла. Хәрби судларда граждан суд эшчәнлеге рус телендә алып барыла.

2. Суд эшендә катнашучы һәм граждан суд эшчәнлеге алып барыла торган телне белмәүче затларга туган телендә яисә ирекле сайланган

теләсә кайсы аралашу телендә аңлатыла һәм аңлатма, бәяләмә бирү, чыгыш ясау, үтенеч бирү, шикаять бирү хокукы, шулай ук тәрҗемәче хезмәтләреннән файдалану хокукы тәэмин ителә.

### 10 статья. Суд эшләре карауның хәбәрдарлыгы

1. Барлык судларда да эшләрне карау ачык рәвештә була.

2. Ябык суд утырышларында эшләрне карау дәүләт серен, баланы уллыкка (кызлыкка) алу серен тәшкил итә торган белешмәләре булган эшләр буенча, шулай ук, әгәр ул федераль законда каралмаган булса, башка эшләр буенча гамәлгә ашырыла. Ябык суд утырышларында эш карау эштә катнашучы һәм коммерция серен яисә закон белән саклanучы башка серне саклау кирәклегенә, гражданнарның хосусый тормышы кагылгысызлыгына яисә ачыктан-ачык фикер алышу эшне дөрес тикшерүгә комачаулык итәрлек йә әлеге серләрне фаш итүгә китерерлек яисә гражданның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга китерерлек башка эшләргә таянучы затның үтенечен канәгатьләндергәндә дә рөхсәт ителә.

3. Карау барышында әлеге статьяның икенче өлешендә күрсәтелгән белешмәләр ачыклану ихтималы булган эшне карауда катнашучы, процессуаль гамәл кылуда катнашучы башка затлар аларны фаш иткән өчен җаваплылык турында суд тарафыннан кисәтелә.

4. Эшне бөтенләй яисә аның бер өлешен ябык суд утырышында карау турында суд расланган билгеләмә чыгара.

5. Эшне ябык суд утырышында караганда эштә катнашучы затлар, аларның вәкилләре, ә кирәкле очракларда шулай ук шаһитлар, экспертлар, белгечләр, тәрҗемәчеләр катнаша.

6. Ябык суд утырышында эш карау суд эшчәнлегенең барлык кагыйдәләрен үтәп карала һәм хәл ителә. Ябык суд утырышында видеоконференц-элемтә системаларыннан файдалану рөхсәт ителми.

7. Эштә катнашучы затлар һәм ачык суд утырышында катнашучы гражданнар суд эшен карау барышын язып барырга, шулай ук аудиоязма чаралары ярдәмендә яздырырга хокуклы. Суд утырышын кинофотога төшерү, видеога яздыру, радио, телевидение һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша трансляцияләү суд рөхсәте белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

8. Суд карарлары, балигъ булмаганнарның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылмаган очракларда, ачык рәвештә игълан ителә.

**11 статья. Граждан эшләрен хәл иткәндә суд тарафыннан кулланыла торган норматив хокукый актлар**

1. Суд граждан эшләрен Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, федераль дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының конституцияләре (уставлары), законнары, дәүләт хакимияте органнарының башка норматив актлары, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә хәл итәргә тиеш. Суд граждан эшләрен норматив хокукый актларда караган очракларда эш әйләнеше гадәтләреннән чыгып хәл итә.

2. Суд граждан эшен хәл иткәндә норматив хокукый акт зуррак юридик көчкә ия норматив хокукый актка туры килми дип билгеләсә, югарырак юридик көчкә ия акт нормаларын куллана.

3. Бәхәсле мөнәсәбәтне җайга сала торган хокук нормалары булмаган очракта суд шундый ук мөнәсәбәтләрне җайга сала торган хокук нормаларын (закон аналогиясен) куллана, ә мондый нормалар булмаганда, эшне гомуми башлангычлардан һәм законнарның мәгънәсеннән чыгып хәл итә (хокук аналогиясе).

4. Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе белән законда каралганнан башка кагыйдәләр билгеләнгән булса, суд граждан эшен хәл иткәндә халыкара хокук кагыйдәләре куллана.

5. Суд эшләрне хәл иткәндә федераль закон яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә чит илләрнең хокук нормаларын куллана.

**12 статья. Эшне карауны якларның ярышучанлыгы һәм тигез хокуклылыгы нигезендә гамәлгә ашыру**

1. Граждан эшләре буенча эш карау якларның ярышучанлыгы һәм тигез хокуклылыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Суд, үзенең бәйсезлеген, объективлыгын һәм гаделлеген саклап, процесс барышына җитәкчелек итә, эштә катнашучы затларга аларның хокукларын һәм бурычларын аңлата, процессуаль гамәлләр кылуның яисә кылмауның нәтиҗәләре турында кисәтә, эштә катнашучы затларга үзләренең хокукларын гамәлгә ашыруда ярдәм итә, дәлилләрне һәрьяклап һәм тулысынча тикшерү, чынбарлыкта булган хәлләрне ачыклау һәм граждан эшләрен караганда һәм хәл иткәндә законнарны дөрес куллану өчен шартлар тудыра.

### 13 статья. Суд карарларының мәҗбүрилеге

1. Судлар суд боерыклары, суд карарлары, суд билгеләмәләре, күзәтчелек инстанциясенең суд президиумы карарлары рәвешендә суд карарлары кабул итә.

Закон белән саклана торган серне тәшкил итүче белешмәсе булган карардан тыш, суд карары электрон документ рәвешендә башкарылырга мөмкин, ул судьяның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана. Әгәр карар суд тарафыннан коллегиаль кабул ителсә, ул эшне караган барлык судьяларның да көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

Суд карары электрон документ рәвешендә башкарылса, әлеге суд карарының бер нөсхәсе өстәмә рәвештә кәгазьдә дә башкарыла.

2. Закон көченә кергән суд карарлары, шулай ук судларның законлы күрсәтмәләре, таләпләре, йөкләмәләре, чакырулары һәм мөрәҗәгатьләре органнары бернинди искәрмәләрсез, барлык дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә иҗтимагый берләшмәләр, вазыйфаи затлар, гражданнар, оешмалар өчен мәҗбүри һәм Россия Федерациясенең бөтен территориясендә һичшиксез үтәлергә тиеш.

3. Суд карарын үтәмәү, шулай ук судка карата башкача ихтирамсызлык күрсәтү федераль законда каралган җаваплылыкка китерә.

4. Суд карарларының мәҗбүрилеге, эштә катнашмаган кызыксынган затларны, әгәр кабул ителгән суд карары белән аларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылса, судка мөрәҗәгать итүдән мәхрүм итми.

5. Россия Федерациясе территориясендә чит ил судларының, чит ил третейский судларының карарларын тану һәм үтәү Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре һәм әлеге Кодекс белән билгеләнә.

## 2 бүлек. СУД СОСТАВЫ. КИРЕ КАГУЛАР

### 14 статья. Суд составы

1. Беренче инстанция судларында эшләр судьялар тарафыннан шәхсән карала. Федераль законда каралган очракларда беренче инстанция судларындагы эшләр өч профессиональ судья составында коллегиаль рәвештә карала.

2. Эшләрне кассация яисә апелляция тәртибендә карау, әлеге Кодекс белән башкача билгеләнмәгән булса, суд тарафыннан рәислек итүче судья һәм ике судья составында гамәлгә ашырыла.

Эшләрне надзор тәртибендә карау Россия Федерациясе Югары Суды Президиумы тарафыннан «Россия Федерациясе Югары Суды турында»

2014 елның 5 февралендәге 3-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон нигезендә билгеләнә торган составта гамәлгә ашырыла.

3. Һәр эшне карау өчен суд составы судьяларның эш күләмен һәм белгечлеген исәпкә алып автоматлаштырылган мәгълүмат системасын куллану юлы белән формалаша. Судта автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдалану мөмкин булмаган очракта, суд составы бүтән тәртиптә оештырылырга момкин, ләкин бу очракта бу оештыруга эшне карауны кызыксыну белдергән кешеләрнең тәэсире булмаска тиеш.

### 15 статья. Мәсьәләләрне суд тарафыннан коллегиаль составта хәл итү тәртибе

1. Эшне суд тарафыннан коллегиаль составта караганда барлыкка килүче мәсьәләләр судьялар тарафыннан күпчелек тавыш белән хәл ителә. Судьяларның берсе дә тавыш бирмичә кала алмый. Рәислек итүче иң соңыннан тавыш бирә.

2. Күпчелек фикере белән килешмәүче судья үзенең аерым фикерен язма рәвештә бәян итә ала, ул эшкә беркетеп куела, ләкин эш буенча кабул ителгән карарны игълан иткәндә укылмый.

### 16 статья. Судьяны кире кагу өчен нигезләр

1. Җәмәгать судьясы, ә шулай ук судья түбәндәге очракларда эшне карый алмый һәм кире кагылырга тиеш:

1) әлеге эшне алдан караганда анда прокурор, суд утырышы секретаре, вәкил, шаһит, эксперт, белгеч, тәрҗемәче буларак катнашкан булса;

1.1. бу эш буенча суд килештерүчесе булган булса;

2) эштә катнашучыларның йә аларның вәкиленең туганы яисә якын кешесе булса;

3) эшнең тәмамлануы белән шәхсән, турыдан-туры яисә башкача кызыксынучы булса йә аның объективлыгына һәм битарафлыгына шик уятучы башка сәбәпләр булса.

2. Эшне караучы суд составына үзара туган булган затлар керә алмый.

3. Судьяга ул карый торган граждан эше буенча кергән процессуаль булмаган мөрәҗәгать турында мәгълүмат булу судьяны кире кагу өчен нигез буларак карала алмый.

### 17 статья. Эшне карауда судьяның кабат катнашуына юл куймау

1. Эшне караучы җәмәгать судьясы әлеге эшне апелляция, кассация яисә надзор инстанциясендә карауда катнаша алмый.

2. Эшне беренче инстанциядәге судта караганда катнашкан судья әлеге эшне апелляция, кассация яисә надзор инстанциясендә караганда катнаша алмый.

3. Апелляция инстанциясендәге судта эшне карауда катнашкан судья әлеге эшне беренче, кассация яисә надзор инстанциясе судларында караганда катнаша алмый.

4. Кассация инстанциясендәге судта эшне карауда катнашкан судья әлеге эшне беренче, апелляция һәм надзор инстанциясе судларында караганда катнаша алмый.

5. Надзор инстанциясе судында эшне карауда катнашкан судья әлеге эшне беренче, апелляция һәм кассация инстанциясе судларында караганда катнаша алмый.

**18 статья. Прокурорны, суд утырышы секретарен, экспертны, белгечне, тәрҗемәчене кире кагу өчен нигезләр**

1. Судьяны кире кагу өчен әлеге Кодексның 16 статьясында күрсәтелгән нигезләр шулай ук прокурорга, суд утырышы секретаренә, экспертка, белгечкә, тәрҗемәчегә дә кагыла.

Эксперт яисә белгеч моннан тыш, әгәр ул эштә катнашучы затларның, аларның вәкилләренең кайсына да булса хезмәт буенча яисә башка төрле бәйлелектә булган яисә хәзер бәйле булса, эшне караганда катнаша алмый.

2. Әлеге эшне алдан караганда прокурор, судья ярдәмчесе, суд утырышы секретаре, эксперт, белгеч, тәрҗемәче буларак катнашкан прокурорның, судья ярдәмчесенең, суд утырышы секретаренең, экспертның, белгечнең, тәрҗемәченең катнашуы аларны кире кагу өчен нигез булып тормый. Суд утырышы секретаренең эшне алдан караганда судья ярдәмчесе булып, яки судья ярдәмчесенең эшне алдан караганда суд утырышы секретаре булып катнашуы аларны кире кагу өчен нигез булып тормый.

**19 статья. Үз-үзен кире кагу турында һәм кире кагу турында гаризалар**

1. Кире кагу өчен әлеге Кодексның 16—18 статьяларында күрсәтел-гән нигезләр булса, җәмәгать судьясы, судья, прокурор, суд утырышы секретаре, эксперт, белгеч, тәрҗемәче үз-үзен кире кагуны игълан итәргә тиеш. Шул ук нигезләр буенча кире кагу эштә катнашучы затлар тарафыннан игълан ителергә яисә суд инициативасы буенча каралырга мөмкин.

2. Үз-үзен кире кагу яисә кире кагу эшне асылы буенча карау башланганчы дәлилләнергә һәм белдерелергә тиеш. Эшне алга таба карау

барышында үз-үзен кире кагу яисә кире кагу гаризасы бары тик үз-үзен кире кагу яисә кире кагу нигезләре шуларны белдергән затка йә эшне асылы буенча карый башлаганнан соң судка мәгълүм булса гына рөхсәт ителә.

3. Үз-үзен кире кагу турында гаризаны хәл итү тәртибе һәм аны канәгатьләндерү нәтиҗәләре әлеге Кодексның 20 һәм 21 статьяларында каралган кагыйдәләр буенча билгеләнә.

4. Кире кагу турында гаризаны канәгатьләндерүдән баш тартылган очракта шул ук зат һәм шул ук нигезләр буенча кире кагу турында гариза бирү рөхсәт ителми.

### 20 статья. Кире кагу турындагы гаризаны хәл итү тәртибе

1. Кире кагу белдерелгән очракта, шулай ук кире кагу белдерелгән затларның, әгәр кире кагылучы аңлатма бирергә теләсә, суд эштә катнашучы затларның фикерен тыңлый.

2. Эшне шәхсән карый торган судья кире кагылу турындагы яисә үзен кире кагу турындагы мәсьәләне киңәшү бүлмәсенә чыкмыйча дәлилле беркетмә билгеләмәсе ярдәмендә хәл итәргә хокуклы.

Судта эшне коллегиаль рәвештә тикшергәндә кире кагу мәсьәләсе киңәшү бүлмәсендә чыгарылган билгеләмә ярдәмендә хәл ителә. Судьяны кире кагу мәсьәләсе кире кагыла торган судья югында судның шушы составы тарафыннан хәл ителә. Берничә судья яисә судның бөтен составы кире кагылган очракта, мәсьәлә тулы составтагы шул ук суд тарафыннан гади күпчелекнең тавыш бирүе белән хәл ителә. Кире кагуны яклап һәм кире кагуга каршы бирелгән тавышлар саны тигез булганда, судья кире кагылган дип санала.

Прокурорны, судья ярдәмчесен, суд утырышы секретарен, экспертны, белгечне, тәрҗемәчене кире кагу мәсьәләсе эшне караучы суд тарафыннан хәл ителә.

### 21 статья. Кире кагу турындагы гаризаны канәгатьләндерү нәтиҗәләре

1. Эшне караучы җәмәгать судьясы кире кагылган очракта эш район суды тарафыннан шушы суд районы территориясендә эш итүче башка җәмәгать судьясына тапшырыла яисә, әгәр мондый тапшыру мөмкин булмаса, югарырак суд тарафыннан башка районның җәмәгать судьясына тапшырыла.

2. Эшне район судында караганда, судья кире кагылган йә судның бөтен составы кире кагылган очракта, эш шул ук судта башка судья